ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» декабря 2023 ел № 378

«2022-2025 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Әгерҗе муниципаль районы комплекслы программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 13.01.2022 елның 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (31.10.2022 елның 262 номерлы карар редакциясендә)

«2014-2025 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 16.10.2013 елның 764 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 21.09.2003 елның 1170 номерлы карарына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2022-2025 елларга хокук бозуларны профилактикалау буенча Әгерҗе муниципаль районы комплекслы программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 13.01.2022 елның 13 номерлы карарына (31.10.2022 елның 262 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Программа чаралары» бүлегенең «2 нче бурыч. Балигъ булмаганнар белән эшләүнең инновацион рәвешләрен һәм ысулларын куллану, балаларны һәм яшьләрне әхлакый һәм патриотик тәрбияләүне активлаштыру һәм камилләштерү» бүлекчәсен түбәндәге пунктлар белән тулыландырырга:

2 нче бурыч: Балигъ булмаганнар белән эшләүнең инновацион рәвешләрен һәм ысулларын куллану, балаларны һәм яшьләрне әхлакый һәм патриотик тәрбияләүне активлаштыру һәм камилләштерү

| Төп чаралар атальшы | Башкар учылар | Төп чаралар ны үтәү вакыты | Ахырг ы нәтиҗә ләрне бәяләү | Индикаторларның әһәмияте | Җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслау (мең сум) |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | күрсәт кече, үлчәү берәмлеге | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2020 (төп) | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 2.5. Балигъ булмаганнарга карата хезмәт законнарының таләпләрен, учреждениеләрдә һәм оешмаларда хезмәтне саклау һәм техника иминлеге кагыйдәләрен үтәүгә тикшерү үткәрергә. | Әгерҗе шәһәре КДН һәм ЗП ӘМР, ЦЗН | 2023-2025 еллар | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 2.6. Укучыларны наркотикларның законсыз әйләнеше өлкәсендә хокук бозуларны кылуга җәлеп итүне кисәтү буенча уртак чаралар үткәрергә. | КДН һәм ЗП ӘМР, ПДН, «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, «УО ӘМР» МКУ | 2023-2025 еллар | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.7. Балигъ булмаганнарның алкоголь һәм спиртлы продукция куллану фактларын ачыклау предметына массакүләм ял вакытын тикшерүне гамәлгә ашырырга, шулай ук балигъ булмаганнарның төнлә өлкәннәрсез йөрүе. | КДН һәм ЗП ӘМР, ОМВД | 2023-2025 еллар | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 2.8. Әгерҗе муниципаль районы буенча күчмә һәм хәер сорашуга омтылучы социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдән балигъ булмаганнарны комплекслы тикшерүләр һәм килүләр үткәрергә. | КДН һәм ЗП ӘМР, ПДН, ОСЗ | 2023-2025 еллар | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 2.9. Иҗтимагый тәрбиячеләр кандидатуралары | КДН һәм ЗП ӘМР | 2023-2025 еллар | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| турында тәкъдимнәр кертү буенча профилактика субъектлары, хезмәт коллективлары һәм иҗтимагый оешмалар белән эшне оештырырга. | | | | | | | | | | | | |

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **Р.М. Латыйпов**